«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 21 августы № 110

«Җир салымы турында» 2017 елның 14 декабрендәге 56 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пункты, шулай ук «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 36 статьясы нигезендә КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- җирле үзидарә органнары, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары, гомуми файдаланудагы мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, аллеялар, яшел утыртмалар, истәлекләр, бәйрәм чараларын үткәрү урыннары, спорт объектлары һәм гомуми файдаланудагы башка объектлар биләгән җир кишәрлекләренә карата җирле бюджеттан финанслана торган бюджет, казна учреждениеләре.».

2. Әлеге карарның 3 статьясындагы 5 абзацы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы ав., Үзәк ур., 4 й.

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай ур., 16 йорт, әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

« Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Олы Карамалы
авыл җирлеге » муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Э.И. Байдамшин